

Ил очен жинелләрдән булмаган 1990 елларда: барысы да талон буенча бирелгән, ипигә дә чикләvләр булган чакта, Ельник районы Лобановка авылында туып-vскән Наиль Равиль улы Шехмаметьевны армиягә алалар.
Наильнен әнисе, Рякия Кәрим кызы истәлекләрен янартып шул еллар турында: «Туганнар, авылдашлар алдында биткә кызыллык тошермәсен дип, тоннәрен ипи пешерәм, камыр ризыклары әзерли идем. Бездә, татарларда, гомер-гомергә урнашылган гадәт буенча, остәл тәм-томнардан ишелеп тошәргә тиеш».
Шул чорда Наиль Равиль улы Шехмаметьевны хәрби хезмәткә алган кон житә: Рузаевка, хәрби комиссариат. Тәvлек әйләнәсендә хәрбиләр. Ниһаять, призывникларнын тозеп, фамилияләрен кычкыра башлыйлар. Шехмаметьевка чират житкәч, офицер: «ун якка», - ди. Шулай итеп Наиль Равиль улы Ерак Кончыгышка- Дальний Востокка киткән командага эләгә. Берничә кон юл vткәч, шәһәргә барып житәләр һәм учебка башлана. Наиль Русский утравына билгеләнә. Бередә Тын океан флотына радистлар әзерли торган уку йорты урнашкан.
Дәрес... анын белән һәр солдатнын истәлекләре дә, яхшы хатирәләре дә кvп. Иртәнге алтыда - подъём, физик зарядка, бәдрәф, иртәнге аш һәм сыйныфлар буенча марш. Нәкъ шулай бередә дә була. Равиль улы Наиль Морзе әлифбасынын һәм башка радистлар очен кирәкле нәрсәләрне шунда ойрәнеп белә. Офицерлар призывникларга радист һонәренен барлык нечкәлекләрен жентеклэп анлаталар. Сvз унаеннан, матрос Шехмаметьевка барысы да жинел бирелә, чонки авылда vскән малай казарма шартларына тиз ойрәнә. Моннан тыш, ул армия алдыннан гына Краснослободск совхоз-коллиятендә механика профессиясенен vзләштерә башлый. Аппаратура белән «син» дә иде, шуна да имеш-мимешләрне ишетмәде. Ярты елга сузылган дәресләр тиз vтеп китә һәм аларны, белгечләр буларак корабльләргә бvлv вакыты житә. Наиль Равиль улы Сахалин утравына база тральщигы булып хезмәт итәргә жибәрелә. Флотилия составында океанга атнага 2-3 тапыр чыга.
Хәрби хезмәттә булган Наиль Равиль улы хезмәтен гади матрос буларак башлый, ә икенче статья старшинасы итеп тәмамлый. Житәкчеләре анын корабльләр белән идарә итv унышларыннан канәгать булган.
Ике ел тиз vтеп тә китә, демобилизация вакыты да житә. Владивостокка кадәр ике сәгать самолет белән, ә аннан сон бер атна буе туган Мордовиягә кадәр язма героебыз поездда кайткан. Очрашу һәрвакыттагыча бик дулкынландыргыч була. Әтисе Равиль Кәрим улы, улы очен горур. Ул ата-бабаларынын намусын хурлыкка тошерми. Әйтеп китәргә кирәк, Равиль Кәрим улы vзе дә дингез авиациясендә хезмәт иткән. Частьләре

Кольский ярымутравында урнашкан була. 1966 елдан бирле кvп еллар vтсә дә, хәрби-дингез флотында хезмәт итv истәлеге буларак, тельняшкасы белән аерылмый ул.
- Шәхсән vзем очен оч бәйрәм бар дип саныйм, - ди Р.К.Шехмаметьев,- бу - Совет Армиясе һәм Хәрби-Дингез Флоты коне, Авиация коне, Хәрби-Дингез Флоты (ВМФ) коне. Мин аларны гаилә белән билгеләп vткәрәм. Улым белән мине дусларыбыз, туганнарыбыз котлый.
...Демобилизациядән сон Наиль Равиль улы Шехмаметьев хәрбилектә хезмәте белән туктатылган укуын совхоз-коллияттә дәвам итә. Механик дипломы ала. «Дружба» колхозында шофер булып эшли. 2013 елда Ельник районы Лобановка авылыннан район vзәгендә йорт салып кvченеп яши башлыйлар. Шунда ул АО «Транспневматика»нын 20нче цехына эшкә урнаша. Инде тугыз ел эшли. Тәртипле, ышанычлы, житәкчелек ягыннан яхшы исәптә. Пенсионер ата-аналары һәм ботен гаиләсе очен ул ышанычлы терәк һәм ярдәмче.

**Наилә НАСЫРОВА тәржемәсе**